ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 өлештә:
а) 6 пунктта «медицина ярдәмен» сүзләреннән соң «һәм санитар хезмәт күрсәтүне» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:
«$8^1$) гавами чараны оештыручының анда катнашучыларның фаразланган саны 500 кешедән артык булачак гавами чараны оештыруга һәм уздыруга акча җыю өчен кулланыла торган банк счеты реквизитлары;»;

2) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9. Гавами чараны оештыручы Федераль закон нигезендә, әгәр ул гавами чараны уздыру турында хәбәрнамәне үз вакытында бирмәгән яисә аңа гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турында (ә Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән очракта, шулай ук гавами чараны уздыруның аның оештыручысы тарафыннан тәкъдим ителә торган бер рәвешен сайлап алу турында) Татарстан Републикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән башкарма хакимият органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан юлланган нигезле тәкъдимне кабул итеп алмаган булса, һәм Федераль законның

12 статьясындагы 4, 5 һәм 7 өлешләрендә каралган очракларда, аны уздырырга хокуксыз була.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 05 март
№ 7-ТРЗ